БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» 09 2024 ел № 232

2025 елга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешләрдә өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

Россия Федерациясенең «Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2025 елга расларга:

кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны;

балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтмәләр коэффициентын 0,75 күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://baltasi.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) һәм Татарстан Республикасы «Балтач район башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2023 елның «20» 09
232 номерлы карары нигезендә
расланган
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларының**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар, бер укучыга бер елга сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җирлеге | 8 280 | 15333 | 18399 |
| | авыл җирлеге | 8680 | 16074 | 19289 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 8179 | 15145 | 18174 |
| | авыл җирлеге | 8 579 | 15887 | 19064 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 8583 | 15895 | 19074 |
| | авыл җирлеге | 8984 | 16636 | 19963 |
| Туризм-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 7976 | 14771 | 17725 |
| | авыл җирлеге | 8376 | 15512 | 18614 |
| Социаль-икътисади | шәһәр җирлеге | 7976 | 14771 | 17725 |
| | авыл җирлеге | 8376 | 15512 | 18614 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |